**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында гражданнар җыены карары**

14 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Боерган авыл җирлегенең Боерган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Боерган авылында юлларны ремонтлауга, каты көнкүреш калдыкларын җыю урынын бетерүгә һәм төзекләндерүгә, кышкы чорда юлларны карап тотуга, җәйге вакытта территорияне чабуга (ягулык-майлау материалларын сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Боерган авыл җирлегенең Боерган авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Боерган авыл җирлеге башлыгы _________ И.В. Малышева

Гражданнар җыены секретаре _________ О.А. Малышева